# Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Сатыш авыл җирлеге Чәбки-Саба торак пунктында

## ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

14.11.2019 № 1

### Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Сатыш авыл җирлеге Чәбки-Саба торак пунктында халык җыены нәтиҗәләре турында

06.10.2003 ел, № 131-ФЗ «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» гы Федераль законның 25.1, 56 статьяларына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясына, Саба муниципаль районы Сатыш авыл җирлеге Уставының 22 нче маддәсенә, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Сатыш авыл җирлеге Советының 25.10.2009 ел, № 25 номерлы «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Сатыш авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау турында " карарына таянып, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Сатыш авыл җирлегенең Чәбки-Саба торак пункты территориясендә халык җыены карар итте:

1. 2020 нче елда Саба муниципаль районының Сатыш авыл җирлеге Чәбки-Саба торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 300 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерергә:

- Чәбки-Саба авылының җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзекләндерү.

3.Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru һәм Саба муниципаль районы Сатыш авыл җирлегенең рәсми сайтында түбәндәге адрес буенча: http://saby.tatarstan.ru/satish бастырып чыгарырга.

Халык җыенында рәислек итүче,
Сатыш авыл
җирлеге башлыгы Ф.Ф.Шафигуллин